ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятнең гомуми принциплары турында» 1256381-7 номерлы федераль закон проекты хакында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятнең гомуми принциплары турында» 1256381-7 номерлы федераль закон проектын карап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы әлеге проектның «Гавами хакимиятне оештыруның һәм аның эшчәнлегенең аерым мәсьәләләрен җайга салуны камилләштерү турында» 2020 елның 14 мартындагы 1-ФКЗ номерлы Россия Федерациясе Конституциясенә төзәтмә турында Россия Федерациясе Законы редакциясендә Россия Федерациясе Конституциясе нигезләмәләрен үстерүгә юнәлдерелгән булуын билгеләп уза. Закон проектында гавами хакимият бердәмлегенең конституциячел нигезләре үстерелә, Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият органнарының үзара хезмәттәшлеге механизмы камилләштерелә, уртак карамактагы мәсьәләләр буенча Россия Федерациясе субъектлары вәкаләтләренә кагылышлы нормалар эзлекле рәвештә бәян ителә.

Шул ук вакытта закон проектының аерым нигезләмәләре демократик федератив хокукый дәүләт буларак Россия Федерациясенең конституциячел корылышының какшамас нигезләренә (Россия Федерациясе Конституциясенең 1 статьясындагы 1 өлеше) каршы килә. Закон проекты, региональ дәүләт хакимияте органнары системасын булдыру мәсьәләләрен җентекләп регламентлаштырып, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары эшчәнлеген хокукый җайга салуның гомуми принципларын (нигезләрен) билгеләүдән китә. Бу исә Россия Федерациясе Конституциясенең 11 статьясындагы 2 өлешендә һәм 77 статьясындагы 1 өлешендә каралган федератив дәүләт принципларын боза.

Шулай, закон проекты авторлары Россия Федерациясе субъекты югары вазыйфаи заты, дәүләт хакимияте органнары атамаларын унификацияләүне (закон проектының 20 статьясындагы 4 өлеше, 32 статьясындагы 3 өлеше), Россия Федерациясе субъектының закон чыгару (вәкиллекле) органы һәм югары вазыйфаи зат вәкаләтләренең бердәнбер мөмкин булган срокларын билгеләүне (закон проектының 7 статьясындагы 11 өлеше, 20 статьясындагы 2 өлеше) тәкъдим итә.

Закон проектының 4 статьясындагы 3 өлеше федераль башкарма хакимият органнарына Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органнарын булдыруда шартларсыз катнашу хокукын бирә. Монда сүз региональ хакимият органнарына тапшырылган федераль вәкаләтләрнең алар тарафыннан гамәлгә ашырылуы очраклары турында гына түгел, ә вәкаләтләрне Россия Федерациясе Конституциясенең 73 статьясында билгеләнгән үз компетенциясе кысаларында гамәлгә ашыру очраклары турында да бара. Анда каралганча, Россия Федерациясе субъектлары, Россия Федерациясе карамагындагы мәсьәләләрдән һәм уртак карамактагы мәсьәләләр буенча Россия Федерациясе вәкаләтләреннән тыш, дәүләт хакимиятенең бөтен тулылыгына ия була.

Закон проектының 39 статьясындагы 2 өлешен, 40 статьясын гамәлгә ашыру регионнарны чынбарлыкта федераль закон чыгару процессыннан читләштерүгә китерәчәк. Күрсәтелгән нормалар белән уртак карамактагы мәсьәләләр буенча федераль законнар проектларына Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан бәяләмәләр тапшыру өчен унбиш көн, ә закон проектының 40 статьясында уртак карамактагы мәсьәләләр буенча закон проектларына төзәтмәләр кертү өчен дә шундый ук срок билгеләнә. Закон проекты авторлары Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару органнары депутатлары күпчелегенең үз вазыйфаларын даими нигездә башкармавын, ә региональ парламентлар утырышларының, кагыйдә буларак, аена бер тапкырдан ешрак узмавын исәпкә алмаган.

Бәян ителгәннәргә нигезләнеп, тәкъдим ителгән федераль закон проектын җитди эшләп бетерүнең таләп ителүен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятнең гомуми принциплары турында» 1256381-7 номерлы федераль закон проектын тәкъдим ителгән редакциядә хупламаска.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына, шулай ук «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятнең гомуми принциплары турында» 1256381-7 номерлы федераль закон проекты буенча алга таба эшләүдә әлеге карарда бәян ителгән фикерләрне исәпкә алып катнашу өчен Татарстан Республикасыннан сайланган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2021 елның 25 октябре
№ 1148-VI ДС